**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Наратлы авыл җирлеге составына керүче Наратлы авылының торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

2019 елның 11 ноябре № 1
17.00 сәг., Мәдәният йорты

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 11 ноябрендә «2019 елда үзара салым кертүгә Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авылы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән , 1 группа инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннарыннан тыш, 200 (йөз) сум күләмендә түбәндәге эш өчен салым алу белән килешәсезме:

- Наратлы авылы Совет урамындагы парк зонасын төзекләндерү өчен

ӘЙЕ ЮК.» дигән сорау буенча уздырылган халык җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә җыенда 528 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 279 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 275 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында 1 катнашучы тавыш бирде.

Җыенда катнашучы 3 кеше тыелып калды.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Наратлы авыл җирлеге составына керә торган Наратлы авылының торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «2020 елда үзара салым кертүгә Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авылы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән , 1 группа инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннарыннан тыш, 200 (йөз) сум күләмендә түбәндәге эш өчен салым алу белән килешәсезме:

- Наратлы авылы  Совет урамындагы парк зонасын төзекләндерү өчен

ӘЙЕ ЮК.» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Наратлы авылы торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында «Интернет» челтәрендә (http://bugulma.tatar.ru, «Авыл җирлекләре» бүлегенең «Наратлин авыл җирлеге» бүлекчәсендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә)

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Наратлы авыл җирлеге башлыгы** **С.А. Дмитриев**